ГЛАВА
ЕРЫКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛАГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

20.04.2022 е. С. Ерыкла № 1

**1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрүгә багышланган чаралар үткәрү турында**

Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 8 маендагы ПУ-360 номерлы Указын, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законны, Алексеевск муниципаль районы башлыгының йөкләмәләрен үтәү һәм Зирекле авыл җирлеге территориясендә урнашкан авыл җирлеге, учреждениеләр һәм оешмалар, иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген координацияләү максатларында:

1. 2022 елда 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган чаралар үткәрү.

2. Расларга:

- оештыру комитеты турында нигезләмә (1 нче кушымта);
- оештыру комитеты составы (2 нче кушымта);
- чаралар планы (3 нче кушымта).

3. Предприятие, оешма, учреждение, иҗтимагый берләшмә җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрүдә актив катнашырга;
- Бөек Ватан сугышы ветераннарының, тыл хезмәтчәннәренең социаль хәлен яхшырту һәм аларга өстәмә ярдәм күрсәтү, шул исәптән көнкүреш шартларын яхшырту буенча чаралар күрергә;
- Алексеевск муниципаль районының Зирекле авылы территориясендә урнашкан Бөек Ватан сугышында катнашучыларның каберлекләрен, мемориалларны һәм һәйкәлләрне тәртипкә китерү буенча эшне оештырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Зирекле авыл җирлеге башлыгы** **В.А.Данилова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районының Зирекле авыл
җирлеге башлыгының
2022 елның 20 апрелендәге
1 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Зирекле авыл җирлегендә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында
Җиңүнең 77 еллыгына әзерлек һәм аны үткәрү буенча
Оештыру комитеты турында
Нигезләмә**

1. Зирекле АҖ 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) Зирекле АҖ 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгына багышланган тантаналы чараларны әзерләү һәм үткәрү максатыннан оештырыла.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы боерыгы, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Оештыру комитеты турында Нигезләмә һәм аның составы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге башлыгы тарафыннан раслана.

4. Оештыру комитетының төп бурычлары түбәндәгеләр:

- 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү буенча чаралар планына (алга таба - Чаралар планы) тәкъдимнәр эшләү һәм уздыру;
- Чаралар планын үтәү белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү буенча АҖ Советы, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;
- Чаралар планын үтәү мәсьәләләрен карау һәм аңа төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәр эшләү.

5. Оештыру комитеты үз алдына куелган бурычларны тормышка ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

- Оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмати материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга һәм алырга;

- Оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә вакытлы эш төркемнәре булдырырга;

- үз утырышларына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларына, Зирекле авыл җирлеге предприятиеләре, учреждениеләре җитәкчеләренә чакырырга.

6. Оештыру комитеты составына Оештыру комитеты рәисе, Оештыру комитеты рәисе урынбасары һәм Оештыру комитеты әгъзалары керә.

Оештыру комитеты рәисе булып Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге башлыгы тора.

7. Оештыру комитеты утырышлары кирәк саен уздырыла.

Оештыру комитеты утырышларын Оештыру комитеты рәисе яки аның кушуы буенча Оештыру комитеты рәисе урынбасары алып бара.

8. Утырышлар көне тәртибен, аларны үткәрү урынын һәм тәртибен Оештыру комитеты рәисе билгели.

9. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

Сорауларны карау нәтиҗәләре буенча Оештыру комитеты утырышында беркетмә тарафыннан рәсмиләштерелә һәм рекомендация характерында була торган карарлар кабул ителә.

Оештыру комитеты карарлары Оештыру комитеты утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Рәислек итүче тавышларның тигезлеге булганда, Оештыру комитеты утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Утырышта Оештыру комитеты әгъзасы булмаганда, ул карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә мәҗбүри кушылырга тиеш.

Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәислек итүче кул куя.

10. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар Зирекле авыл җирлегенең кызыксынган затларына җиткерелә.

11. Оештыру комитеты эшчәнлеген матди-техник, документация ягыннан һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне Зирекле авыл җирлеге башкарма комитеты башкара.

**Башкарма комитет сәркатибе** Хаму **Л.И.Хәметшина**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районының Зирекле авыл
җирлеге башлыгының
2022 елның 20 апрелендәге
1 номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлегендә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 77 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча Оештыру комитеты составы**

Данилова В.А. Зирекле АҖ башлыгы, **оештыру комитеты рәисе**

Хәметшина Л.И. Зирекле АҖ башкарма комитет сәркатибе, **оештыру комитеты рәисе урынбасары**

**Оештыру комитеты әгъзалары:**

Устимова М.В. Зирекле ТГБМ директоры
Епифанова В.И. Зирекле ТГБМ директор урынбасары
Краснова И.А. Зирекле АМЙ директоры
Серова Е.Ф. И.Муллино авыл клубы мөдире
Фәхретдинова Г.Г. Мораса авыл клубы мөдире
Тимофеев Г.К. Зирекле АҖ башлангыч оешмасының ветераннар Советы Рәисе

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районының Зирекле авыл
җирлеге башлыгының
2022 елның 20 апрелендәге
1 номерлы боерыгына
3 нче кушымта

2022 елның 9 Маенда Җиңүнең 77 еллыгын
бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрүгә
**ЧАРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ**

| №№ | чараның исеме | үткәрү датасы | үткәрү өчен җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, аларның яшәү урыны турында мәгълүматларны актуальләштерү. Тормыш хәлен өйрәнү, сәламәтлек торышы. | 18.04.2022-19.04.2022 | АҖ башлыгы, ветераннар Советы |
| 2 | Зирекле, Кызыл Уракчы, Мораса авылларында Бөек Ватан сугышында һәлак булган якташларга һәйкәлләрне төзекләндерү. | 18.04.2022-25.04.2022 | АҖ башлыгы, ТГБМ, АМЙ, а.клубы |
| 3 | Ветераннарның өйләренә барып тормыш хәлләрен ачыклау, әхлакый ярдәм күрсәтү, бүләкләр тапшыру максатында бару. | 20.04.2022 | АҖ башлыгы, ветераннар Советы, ТГБМ, АМЙ, а.клубы |
| 4 | Россия һәм республика акцияләрендә катнашу<br>«Хәтер бакчасы» агач утырту<br>«Җиңү тәрәзәләре» тәрәзәләр-дәге рәсемнәр<br>«Рәсем конкурслары»<br>«Китап күргәзмәсе» һ. б.<br>(***<u>мәгариф һәм мәдәният учреждениеләре планнары буенча</u>***) | Апрель-май 2022 е. | ТГБМ, АМЙ, а.клублары |
| | **Төп тантаналы чара 9 МАЙ 2022** | | |
| 5 | Үлемсез полк | 9 сәг. 30 мин | АҖ башлыгы, ТГБМ |
| 6 | «Хәтеребезне еллар узу белән сызып ташларга ярамый» | 10 сәг. | АҖ башлыгы, ТГБМ, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | митингы<br>- «Яшь армияче» клубының парады, сафка басуы<br>- кунак ветераннар чыгышы<br>- үзешчән сәнгать номерлары<br>- бер минут тынлык<br>- веноклар кую<br>- (Мораса авылында митинг, Кызыл Уракчы авылында митинг | 9 сәг.<br>9 сәг. 30 мин | АМЙ, ветераннар Советы |
| 7 | «Сугыш кайтавазы» концерты | 11 сәг. | АМЙ, авыл клублары |
| 8 | «Сезнең алда баш иябез..» тыл хезмәтчәннәре өчен ут | 12 сәг. | АМЙ |
| 9 | Тыл хезмәтчәннәре өчен агитбригада.<br>Ветераннарга бару һәм аларны котлау, «Поём двором» («Җырлы ишегалды») акциясе кысаларында концерт номерлары | 13 сәг. 30 минуттан алып | АҖ башлыгы, АМЙ, авыл клублары |